**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2015 елның «14» декабреннән № 350

**«Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында»**

Яңа ел бәйрәмнәренең, гражданнарның, физик һәм юридик затларның, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2015 елның 3 декабрендәге 913 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. 2015 елның 15 декабреннән 2016 елның 10 гыйнварына кадәр Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режимкертергә.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

ведомство карамагындагы учреждениеләрдә Яңа ел бәйрәмнәренә әзерлек һәм уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлеге белән яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын килештерергә;

Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны янгын-техник минимум программалары буенча укытуны оештырырга;

Яңа ел бәйрәм чараларын уздыру чорында дежур персоналның санын арттырырга;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең ябык биналарында ут эффектлары булган пиротехника әйберләрен саклауны һәм аларны куллануга юл куймаска;

3. Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

Яңа ел бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында халык, юридик затлар арасында аңлату эшләре алып баруны оештырырга;

янгын сүндерүгә яраклаштырылган техника белән тәүлек буе ирекле янгын сүндерү хезмәте әгъзаларының дежурлыгын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;

оператив хезмәтләрне һәм оешмаларны яңа ел бәйрәм чараларына һәм түбән температура чорына әзерләү мәсьәләләре буенча фикер алышырга;

тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларына ремонт ясарга, елның кышкы чорында су алу өчен су башняларын, табигый сулыкларны туңдырмый торган буралар белән җиһазландырырга, су чыганакларына керү юлларын кардан арындырырга;

халыкка шәхси автотранспортны турыдан-туры янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары янында калдырмаска, кирәк булганда янгын автомобильләренең сулык чыганакларына килүен кыенлаштыра торган автотранспортны эвакуацияләүне оештырырга кирәклеге турында хәбәр итәргә;

урам чыршыларын бизәүдә сертификацияләнгән электр гирляндаларын файдаланырга;

пиротехник эшләнмәләрдән файдаланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү буенча чаралар турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга;

кирәк булган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыю билгеләргә.

4. Тәкъдим итәргә:

Пиротехника әйберләрен җитештерү, саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә» пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карарын һәм «Пиротехник эшләнмәләр куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламентын кабул итү хакында» Таможня берлеге комиссиясенең 2011 елның 16 августындагы 770 номерлы карарын үтәүне тәэмин итәргә;

юридик затларга һәм автозаправка станцияләрен һәм комплексларын эксплуатацияләүче индивидуаль эшмәкәрләргә электр гирляндаларын һәм шартлаткыч саклау таләп ителми торган башка иллюминацияләрне, югарыда күрсәтелгән объектларның территорияләрен һәм биналарын бизәгәндә, кулланмаска.

5. Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлегенә, Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе һәм Россия ГТХМ Баш идарәсенең районара бүлегенә тәкъдим итәргә:

яңа ел бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга;

Яяңа ел һәм раштуа бәйрәм чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алырга;

балалар катнашында яңа ел тамашаларын үткәрү урыннарының һәм объектларның янгынга каршы торышын тикшерергә;

пиротехник эшләнмәләрне саклау һәм сату урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшерергә;

янгын чыгу очрагында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында бәйрәм чаралары уздыру объектларының хезмәт күрсәтүче персоналына инструктаж үткәрергә һәм үзләштерүне янгын чыккан очракта гамәлдә эшләп карарга;

бәйрәм чараларын үткәрү объектларында янгыннарны сүндерү планнарына һәм карточкаларына төзәтмәләр кертүне, шулай ук әлеге объектларда янгынга каршы су чыганакларын тикшерүне оештырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **В.Н. Семеняк**